ГЛАВА УРУССИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с. Старые Уруссу, ул. Советская, д.16в,
423960

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Иске Урыссу авылы, Совет урамы, 16в йорт,
423960

Тел.: (85593) 4-42-31, факс: 4-41-52, e-mail: Uruss.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№4 2019 елның 08 ноябре

# Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Каклы Күл авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Уставының 14 статьясы нигезендә, Ютазы муниципаль районының «Урыссу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. 2019 елның 21 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Каклы Күл авылы, Елга урамы, 18А нче йорт адресы буенча урнашкан КФҮ бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Каклы Күл авылы гражданнары җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

"Сез 2020 елда Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Каклы Күл авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан тыш, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәт итүгә чакырылучылардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- Каклы Күл авылында юлларны кардан чистарту;
- Каклы Күл авылында зират ихаталарын алыштыру (сатып алу, килешү буенча эшкә түләү)

« ӘЙЕ» “ЮК".

3. Урыссу авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

4. Әлеге карарны ул кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында www.yutaza.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

“Урыссу авыл җирлеге”
муниципаль берәмлеге
Башлыгы вазифаларын башкаручы Ф.Г. Әминова